ISSN 0136-7110

Чаян



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ ГЫЙНВАР * 2020 * КАЗАН

1

Александр ШУЛЬПИНОВ





АННАН-МОННАН ИНФОРМ

СОҢГЫ ХӘБӘРЛӘР

• Икътисад буенча, Нобель премиясе, капиталның беренче туплану этабыннан соң, аны күз ачып йомганчы югалту этабы баруын исбатлаучы Рәсәй галимнәренә бирелүен игълан иттеләр.

• Рәсәй һәм Украина газга газ каратып, ягъни күзгә-күз газ төтене җибәреп сөйләшүләр алып баралар.

• Галәмәт күпкә киткән бәйрәмнәрнең санын кыскарту исәбеннән, Каравылчылар көнен Халыкара Кроссвордлар көне белән берләштерергә уйлыйлар.

• Росгвардия кәгазь стаканнар җитештерү заводын яптырды.

• Импотентларның хокукларын чикләү турындагы Закон проекты кертелүгә депутатлар әллә ни активлык күрсәтмәде.

• Воронеждагы Пенсия фондының җитәкчесе үзенең әтисенә ике ел буе 145 мең акча күчереп барган. Әлеге пенсионер Рәсәйне аякка баса башлады дип уйлап йөргән.

• Психбольницада ятучы авыру, Наполен булып йөрүдән баш врач дәрәҗәсенә күтәрелеп, галәмәт зур карьера ясаган.

• Хастаханәләрдә, медицина җиһазлары яңарту программасы кысаларына кертелеп, бахилалар сату автоматлары куелган.

• Алфавиттагы хәрефләрнең гадәти урнашуларын яңача тәртиптә бирү тәкъдим ителгән – ЙЦУКЕНГШЩЗХФЫВАПРОЛДЖЭЯЧСМИТЬБЮ.

• Паркта "Көлке бүлмәсе" ачканнар. Яңа аттракцион белән шундук наркоконтроль кызыксына башлаган.

• Өлкәннәр йорты тирәсенә махсус өйрәтелгән күкеләр җибәреләчәк, алар андагы яшәүчеләргә өмет чаткылары уятып торачак.

• Коллекторларның корпоративында ипотекалары түләнмәгән артистлар чыгыш ясаган.

• Алимент түләмәүчеләрне беспилотниклар белән эзләячәкләр.

• Хастаханә ишегалдында шартламаган клизма табылган.

• Үз эшенә салкын караучы сурдотәрҗемәче яңалыклар алып бару урынына, атна буе үзенең машинасын сату турында игълан биреп барган.

• Психбольницаның баш табибы, телевидениедән ток-шоу тапшыруында үзләреннән качып киткән ике пациентын таныган.

• Пациенткаларының шәхси мәгълүматларын саткан гинеколог тоткарланган.



ШОМБАЙ *болай диде...*

Хөрмәтле Чаян! Ел ахыры безгә көтелмәгән яңалык алып килде – допинг тирәсендә яңадан ыгы-зыгы купты. Безнең спортчыларны чираттагы тапкыр халыкара ярышларда катнашу хокукыннан мәхрүм иттеләр. Хәзер барысы да гаепләләрне эзли башлады – моңа кем гаепле: чиновникларммы, спортчыларммы, әллә шул ук Родченковмы? Һәм безгә нишләргә – шап итеп ишекне ябып китәргәме, әллә әләмсез һәм гимнсыз ил сыйфатында чыгыш ясаргамы? Бу хәлләрдән соң СССР заманнары искә төшә – ул чакта безнең белән исәпләшәләр иде, ә допинг турында ишеткәнебез дә юк иде...

Л. ВАЗЫЙХОВ

АРЧА

Укучының хатын укып чыккач, Шомбай ага болай диде: **«Ул чакта безнең спортчылар кулында дөньядагы иң көчле допинг – совет власте бар иде...»**

КАРЛАР ЯУМЫЙ


Ява карлар, ашыккандай җирнең
Караларын акка күмәргә...

(Зөлфәт)

Карлар яумый хәзер.
Бүген җирдә
Чәчрәп ята дөнья шакшысы.
Шакшы илгә саф җилләр дә керми,
Төшми хәтта кояш яктысы.
Әрнеп язган шигырьләрең, Зөлфәт,
Йомшак әрләү булып тоела.
Үзгәрде шул дөнья – хәзер һәр көн
Җанга яра булып уела.
Ил карасы җир карасы булып
Ябышадыр талган аякка.
Котылып һич булмый ул афәттән –
Саклап тора безне һәр якта.

...Их, узасы иде бер генә кат
Таптап илнең чиста ак карын,
Һәм юасы иде табаннардан
Сеңеп каткан пычрак дөньясын!

Ринат АБЗАЛОВ



Александр АЛЁШИН



Ринат АБЗАЛОВ

Шакшы янарыш

Соңгы вакытларда илдә онытылып барган сүгенү гадәтенең яңарышы күзәтелә. Әгәр дә элегрәк бу яман күренеш тәрбиясез җитәкчеләргә һәм ярымисерек йөкчеләргә генә хас булган булса, бүген инде сыра исе сеңгән урам малайларыннан алып, мәктәп кызларына кадәр иң әшәке сүзләр белән сүгенә. Беренчеләре, гомумән, аннан башка ике сүз ялгый белмәсә, икенчеләре әшәкелек белән сугарылган телевидение тапшыруларыннан үрнәк ала. Күңелсез булса да, әйтмичә булмый: халыкның культура дәрәҗәсе аска тәгәри. Ә сизгер «мәдәният эшлеклеләре» моннан оста файдалана...

Менә өр-яңа мисал. Көз көне Прагада Дмитрий Быковның «иҗат кичәсе» булып узган. Сүз иреге сөючеләрнең рухи остазы шигырьләрен укып, ил һәм үзе турында сөйләп, кешеләрнең күңелен ачарга маташкан ул. «Әдәби әсәр»ләр мул итеп пычрак сүзләр белән «баетылган», ә эчтәлеге – кичәдә катнашучыларның берсе әйтүенчә, шакшы чүп чокыры...

Дөресен әйткәндә, бу мине һич тә гаҗәпләндермәде. Күрәсең, хәзерге хакимнәр тарафыннан өстән төшерелгән күрсәтмәдер: әгәр дә син сүгенмисең икән, димәк, үз кеше түгел. Бүгенге көндә рус эстрадасында да, телевидениедә дә, әдәбиятта да, Интернетта да пычрак теллелек хөкем сөрә. Ә аны халык күңелләренә җиткерүчеләр булып күренекле шәхесләр чыга.

Шундыйларның берсе – мәдәни мәркәзебездә туып-үскән һәм сүгенүле чыгышлары белән дан яулган Сергей Шнуров. «Ленинград» төркеме җитәкчесе халыкка тел пычрагын турыдан-туры сәхнәдән сибә. Бу өлкәдә ул зур уңышларга ирешкәндер, күрәсең, Россиянең беренче сүгенү остасы – Дәүләт Думасының мәдәният комитеты әгъзасы. Нишлисең бит, мәдәнияте нинди булса, әгъзалары да шундый...

Бөтен Россия халкына билгеле Ксения Собчак та тел шакшылыгы буенча алдынгылар сафында бара. Аның бай тел «сөйләме» даими рәвештә бик тә үтемле итеп аталган «Сак булыгыз, Собчак!» тапшыруларында яңгырый. Күптән түгел ул анда җырчы Влад Топаловның хәләле, Украина сәхнәләрендә җырлап көн күрүче, күптән түгел әни булган Регина Тодоренко белән әңгәмә оештырган. Тапшыруның беренче мизгелләреннән үк яшь әни эфирга үзенең «тел байлыгын» сибәргә тотына. Ә Собчак ничек? Югары белемле философия белгече булган ханым аның белән ризалашып, башын селкеп утыра. Ксениянең озак еллар буе түбән дәрәҗәле тапшыруларда эшләү тәҗрибәсе әрәмгә китмәгән, күрәсең...

Шулай да, колак шиңдергеч, җанны әрнетә торган ташкын белән нишләргә соң? Тагын бер эшләми торган закон кабул итәргәме, почмак саен «Сүгенү тыела!» дигән язулар элеп чыгаргамы, әллә зур штраф белән янаргамы? Әйтергә кирәк, соңгысының файдасы тиеп куюы мөмкин. Мәсәлән, Новосибирск шәһәрендә яшәүче Евгений Гуляев әлеге дә баягы Сергей Шнуровны судка биргән – сәхнәдән яңгыраган сүгенү аның җанына хуш килмәгән. Тамашаны ташлап киткән ир кеше моның өчен 300 мең сум таләп иткән.

Гуляевның дәгъвасы өлешчә генә канәгатьләндерелгән: суд концерт оештыручылардан 2,5 сумлык билет бәясен, мораль зыян өчен 2 мең һәм 2,2 мең сум штраф түләткән. Бик кызганыч! Россия эстрадасының иң бай артистына катырак җәза да артык түгел иде.

Әйтергә кирәк, Россия буенча Новосибирск кешеләре шакшы теллелек белән көрәшнең алгы сафларында бара. Өч ел элек шәһәр судында моңа охшаш эш каралган иде инде. Ул чакта концерт оештыручыларына 40 мең сум штраф салганнар иде. Бу күп түгел, әлбәттә. Тик шулай да сәхнәдән пычрак сибәргә яратучы артистлар, матди чыгымнарга дучар була башласалар, телләрен бераз тыярга өйрәнерләр иде. Ә аннан соң, бәлки, башка шакшы телләрне дә тыярлар иде...

Марат АКСАНОВ





Михаил ЛАРИЧЕВ



Виктор ФЁДОРОВ



• • •

Тәҗрибәле карбыз сатучы улының маңгаена бер чиртү белән, аның имтиханга әзерме-түгелме икәнен ачыклый ала.

• • •

Хатын-кызларның ике бәласе бар: көзге һәм үлчәү. Паспорт та бар, әлбәттә, тик аны бик җиңел югалтырга була…

• • •

Бер ир машинасын шулхәтле җайсыз итеп туктатып куйган ки, машина өстенә "җүләр хатын" дип язганнар хәтта.

• • •

Эшкә барыр алдыннан башта Интернет почтасына кереп, кайда бөке юклыгын карыйлар. Һәм шулай итеп тагын да зуррак бөке ясыйлар.

• • •

Хатыннарның кибеттә йөрү тизлеге – сәгатенә биш мең.

• • •

Әгәр дә кәгазь акчаларга шпаргалка язып имтиханга керсәң, укытучының синнән аны тартып алырга тырышуы ришвәт алу булып саналачак.

• • •

Әти-әниләр безне бала чактан ук таныш булмаган кешеләргә ышанмаска өйрәтәләр. Ә танышларга ышанмаска без соңрак үзебез өйрәнәбез…

• • •

– Улың сиңа бөтенләй охшамаган.
– Безнең гаиләдә барысы да шундый. Мин үзем дә әтиемә бер бөртек тә охшамаган.

• • •

Әле генә бер әбинең внедорожникның руль артында утырганын күрдем. Ул аны ничек алган икән? Пешергәнме? Бәйләгәнме? Әллә хастаханәдә чиратта торган өчен алганмы?



Ни дисәң дә, бездәге түләүсез медицина нәтиҗәләрәк. Түләүлесе күп акча туздырган саен, сәламәтлекне какшатуга гына китерә, ә түләүсезе, аның белән очрашырга язмасын дип, теләсә дә, теләмәсә дә сәламәтлек турында кайгыртырга мәҗбүр итә.

Алексей МАМАЕВ



Михаил ЛАРИЧЕВ



Игорь КИЙКО



КҮЗӘТҮЛӘР

Иң начар диагнозларны патологоанатомнар куя.

Түләүсез медицина кешеләр акчаларын түләүле медицинага теләбрәк бирсеннәр өчен кирәк.

Медицина институтыннан начар укыган өчен генә түгел, ә аңлаешлы кул язуы өчен дә куып чыгарулары мөмкин.

Медицина киң адымнар белән алга атлый, тик кешеләр аның артыннан өлгерә алмый.

Безнең илдә авырыр өчен ат кебек таза булу кирәк.


Виктор ФЁДОРОВ

ЧИТТӘН ТОРЫП ДӘВАЛАУ

Татарстанда бер пенсионер баш авыртуын бик озак «читтән торып» дәвалаган. Гадәти медицинага ул ышанмаган һәм телевизордан им-томчы рекламасы күреп, шундук аңа мөрәҗәгать иткән. Пенсионер җиде ай буе дәвачының киңәшләрен төгәл үтәп, аның картасына акча күчереп барган. Сумма 100 мең сумга якынлашып, авыртулар берничек тә үтмәгәч, бичара авыруның күңелендә шик туа башлаган. Полиция хезмәткәрләре дә аның шиген уртаклашкан һәм хәзерге вакытта җинаять эше кузгату мәсьәләсе хәл ителә.


Виктор ФЁДОРОВ



МЕДИЦИНА МОГҖИЗАСЫ

Татарстанда... онкология диагнозлары сату буенча җинаять эшләре кузгатканнар. Соңгы стадиядәге яман шеш белән авыручыларның озак яшәвенә медик-социаль экспертиза хезмәткәрләре игътибар иткән. Тикшерү вакытында "инвалид"ларның беркайда да дәваланмаулары, шуңа да карамастан, үзләрен бик яхшы хис итүләре ачыкланган. Тиздән бу "могҗизага аңлатма да табылган: диагнозлар ялган булып чыккан. "Авырулар" моның өчен 150 дән 300 мең сумга кадәр акча түләгәннәр икән. Хәзергә 18 шундый очрак ачыкланган.

ШӘП ЯЛ ИТКӘННӘР!

Казанның 19 нчы номерлы гимназиясендә ике ел эчендә ата-аналардан... 50 миллион сум акча җыйганнар. Аңа урын җиңел табылган. Директорга һәм аның урынбасарларына ай саен 100 мең сум премия түләнеп барган, ә җыелган акчаның 700 меңе укытучыларның Гарәб Әмирлекләренә барып кайтуына тотылган. Чит илгә сәяхәт рәсми рәвештә педагогларның халыкара олимпиадаларда катнашкан өчен кызыксындыру чарасы булып теркәлгән булса да, бу хәлләрдән соң Татарстан мәктәпләренең ирекле акча фондлары өстеннән дәүләт күзәтүе кертелгән.

ИРЕКСЕЗ ИСБАТЛАУ

Татарстан пенсионерларына үзләренең исән икәннәрен исбатларга туры киләчәк. 85 яшьтән өлкәнрәк булган кешеләргә Пенсия фонды бүлекчәсеннән "мәгълуматларны яңарту" таләбе белән, чакыру кәгазьләре килгән. Фонд хезмәткәрләре белдерүенчә, алар бу адымга барырга мәҗбүр, чөнки кайсыбер туган вафат булган пенсионерлар өчен акча алалар икән. Картларга исән икәнлекләрен исбатларга еш туры килерме – монысы әлегә билгесез.

ЯЛКАУ ЯКЛАУЧЫ

Әлмәттә бер адвокат ханым клиентын яклау урынына бу вакытта үз эшләре белән шөгыльләнгән. Ә клиентка утырышларның ничек узуы турында уйдырмалар сөйләгән. Эш оттырылгач, бичара хөкем ителүче үзен беркемнең дә яклаган булмавын ачыклаган. Хәзер инде яклаучы үзе җавапка тартылган. Ялкаулык һәм эшкә йөрмәвен аклаучы ялган документлар ясаганы өчен, юрист өч елга колониягә озатылган.



ХӘЙЛӘКӘР КОНДУКТОРЛАР

Хөрмәтле редакция! Бик сәер, иҗтимагый транспортларында кондукторлар булуга карамастан, соңгы вакытларда билетсыз йөрүчеләр саны бермә-бер арткан. Хикмәт нәрсәдә икән соң? Сәбәбе – кайбер кондукторларның яшерен билет бизнесы белән шөгыльләнүдә.

Быел гына да әлеге астыртын эшләре өчен 76 кондукторны эшеннән алдылар. Әмма аларның схемасы әле дә яши бирә: эшне дөрес оештырмауга сылтаулар, ялган билетлар, төзәтелгән даталар һ. б. Кондукторның пассажирларга билет алып тормыйча гына юнь бәягә бара алуларын шыпырт кына сиздерүләре турында әйтеп үтәргә була. Ә андый "исәпле" пассажирлар да әз түгел хәзерге заманда. Тик менә андый уй-фикер бик кыйммәткә төшә шул. Транспорт хуҗалары, керемнәр транспортны ремонтлауга да җитми, дип, бәя күтәрмәкче булалар. Әлегә, транспорт низагы хәл ителмәгән дәвердә һәр билет бәхетле булырга мөмкин. Дөрес, әлегә кондукторлар өчен генә...

Г. РӘШИТОВА

КАЗАН

СУДА АККАН ЮЛЛАР

Хөрмәтле "Чаян"! Җимерелеп беткән юлларны тәртипкә китерәм дип, нәрсә генә эшләмиләр бездә хәзер. Юл чокырларын кирпеч, вак ташлар, такта, иске паласлар, хәтта, бәрәңге белән дә томалыйлар.

Адоратский урамы 15 нче йортта яшәүчеләргә бәхет елмайды дип уйлаган идек без. Йорт мәйданын асфальт валчыклары белән томаладылар. Технология белән эшләделәр. Әмма беренче яңгырга хәтле генә булды сөенечебез. Ишеп яуган яңгыр агызды безнең асфальтыбызны. Кинәт төшкән салкын һава чокырларны тагын да тирәнәйтте.

Хәзер безнең йорт ремонт булган мәлгә караганда да коточкычрак хәлдә калды. Аны бөтенләй ясамасалар хәерлерәк булыр иде. Белгәнебезчә, машина тракторсыз үз җае белән генә чокырдан чыгу юлын таба икән, димәк, юл начар дигән сүз түгел әле...

Р. АРСЛАНОВ

КАЗАН



Валерий ТАРАСЕНКО



Александр КОСМЫЛИН



Илдар НӘФИЕВ

Рафилҗан ХӘЛИЛҖАНОВ

Яңа ел тәкәсе

Яңа ел алдыннан гына берәүдән фатир сатып алдык. Аны бик зур начальник булган дип әйттеләр. Безнең өчен барыбер – зур ни, кечкенә ни... Фатирның зурлыгы безгә бик җиткән. Шатлыклы вакыйганы Яңа елга билгеләдек. Һәм иң якын дусларны кунакка чакырдык. Якын булмаганнары үзләре килә аның.

Бәйрәм өстәле артына утыруыбызга – ишектә кыңгырау. Ачып җибәрсәк, кемнәр дип уйлыйсыз инде?! Кыш бабай белән Кар кызы!

Безнең шатланганны күрсәгез!.. Көтелмәгән сөенеч!.. Кунакларны сыйларга керештек. Бишенче рюмканы күтәргәндә Кыш бабай кинәт буш кул белән килмәүләрен исенә төшерде. Капчыгында актара торгач, матур тасма белән уратып бизәлгән тартма тартып чыгарды – хәйран зур үзе...

Ун минут та үтмәгәндер, яңадан ишектә кыңгырау тавышы. Тагын бер Кыш бабай белән Кар кызы. Аларны да табынга чакырдык...

– Монысы хуҗаларга бездән! – дип, тегеләрнекенә караганда да дәүрәк тартма чыгарып, өстәлгә куйды...

Боларын гына озаткан идек, бусагада тагын кар вәкилләре пәйда булды. Хәйран калдык – бүләк тә бүләк!..

Ә инде Яңа ел килгәнне белдереп, Кремль сәгатьләре суккач нәрсә башланганны белсәгез! Ишекне ачып ябарга өлгерми идек. Ниндидер ягымлы кешеләр бер кап шампан шәрабы керттеләр, икенчеләре – тәпән белән бал, өченчеләре – тере тәкә. Күп тә үтмәде безнең фатир музейга әйләнгән кебек төс алды, хәтта терлек абзарына охшатып куйсаң да була. Ә бүләкләрне һаман китерәләр дә китерәләр бит.

Ниһаять, яңа ел иртәсе туды. Айныган баштан без әлеге бүләкләрне тикшерә башладык, чутына чыгардай түгел. Үрмәләп йөрибез, инде тәкә белән маңгайга маңгай бәрелешкәч кенә аңга килдек.

Беренче тартманы ачып карауга күзләребез маңгайга менде, чөнки анда салынган открыткада язылганча, бу бүләкләр безгә түгел, ә фатирын сатып киткән элеккеге хуҗасына юлланган булып чыкты. Икенче тартмада да шулай. Бал да, теге тәкә генә адрессыз...

Безгә чит-ят кешенең малы кирәк түгел, һәм мин бу фатирның элеккеге хуҗасын – Вәли Вәлиевичны эзләргә тотындым.

Таптым. Ул коттеджлар бистәсендә булып чыкты. Ләкин капкаларын күпме генә дөбердәтсәм дә, ачучы булмады. Күршеләренә шалтыраттым, белештем, әйттеләр. Яңа ел алдыннан гына ришвәт алган өчен аны КПЗга япканнар икән. Бер айдан соң тагын бер нәрсә белдем: чыгарганнар, ришвәт алмаган булган икән.

Шулай икәнен белгәч, әлеге дә баягы Яңа ел мөлкәтен үземә калдырдым, шул исәптән, инде ашыгып ашалган тәкәне дә...





• • •

Кыз – егетенә:

– Беләсеңме, кадерлем, ә мин бит синең янга әкияттән килдем.

– Нинди әкияттән?

– Матур әкияттән.

– Нәрсә, куып чыгардылармыни?



Валерий ТАРАСЕНКО

Урманда сыра артыннан озын чират тора. Куян һаман чиратсыз узарга маташа. Бүре аны колагыннан күтәреп ала: «Нәрсә, Бүредән алда үтмәкче буласың?» Куян аңа: «Риза түгелсең икән, әйдә, куак артына барып сөйләшеп килик!» Китәләр болар. Бер минуттан куян тагын чират боза башлый. Аю аны колагыннан эләктереп ала: «Нәрсә, Аюдан алда кермәкче булдыңмыни?» Куян исе китмичә генә: «Әйдә, куаклар артына барып сөйләшик». Аю белән Куян китеп бара. Бераздан Куян тагын чират башына тыгыла башлый. Монда инде Арыслан чыгырыннан чыга: «Син нәрсә, бөтенләй ычкындыңмы әллә?» Куян һич тә курыкмыйча: «Әйдәле, куаклар артына барып килик!» Болар куаклар артына кереп китәләр, ә анда Аждаһа тора. «Куян, күпме ит ташырга була инде? Сыра кайчан булачак?!» – ди.



Илдус АЗИМОВ

Александр СЕРГЕЕВ



Анастасия ВАСИЛЬЕВА





ПЕДАГОГИК МАКСАТ

Мәскәү шәһәрендәге бер укытучы, шартлаткыч җайланма тапкан очракта үзеңне ничек тотарга дигән темага, ачык дәрес үткәрергә исәп иткән. Ул укучыларны зоопаркка алып барган һәм күренә торган урынга муляж ташлап калдырган. Тик әсбап белән укытучы артык тырышкан – консерва банкасына чыбыклар һәм хәтта таймер да урнаштырган. Укучыларга кадәр "бомба"ны зоопаркка башка килүчеләр тапкан һәм полиция чакыртканнар. Педагогик эшчәнлеге өчен укытучыга карата административ эш ачканнар.

БАКЧА РЭКЕТЫ

Уфадагы балалар бакчасының мөдире эшчеләренә премия түләп, тик бакча кирәк-яракларына дип, акчаны кире ала торган булган. Аннары, тәмен татыгач, хезмәт хакларының да бер өлешен ала башлаган. Телсез-тешсез генә премияләрен биреп баручы хезмәткәрләр хезмәт хакын югалтуны күтәрә алмаганнар һәм полициягә хәбәр иткәннәр. Тикшерү ачыклаганча, мөдир кесәсенә салган акча 700 мең сум тирәсе була. Бакчаның кирәк-яракларына дәүләт һәм ата-ана акчасы тотылганы ачыкланган.

ШӘФКАТЬСЕЗ АВТОЗАК

Коми Республикасының коррупция өчен хөкем ителгән элеккеге түрәсе Павел Марущак автозакларга жалоба биргән. Тикшерү барган дүрт елда, ул СИЗОда утырган. Бу вакыт эчендә экс-түрә суд утырышларына 1600 сәгать хөкем ителгәннәрне йөртә торган машинада үткәргән. Гариза бирүче әйтүенчә, машина кеше йөртү өчен бөтенләй дә җайланмаган. Анда урындыклар уңайсыз, вентиляция юк икән. Үзенең җан кичерешләрен Марущак 15 млн. сумга бәяләгән, тик суд системасының камил булмавын искә алып 2 млн. 250 мең сумын гына сораган.

ЯШЕРЕН СӘНГАТЬ

Екатеринбургта сәнгать галереясында рәссамнарга рәсемнәренә төзәтмәләр керттергәннәр – шәрә хатын-кызларның кызыктыргыч урыннарын капларга кушканнар. Рәссамнар оят урыннарга стикерлар ябыштырырга мәҗбүр булганнар. Күргәзмәнең директоры Андрей Чайников аңлатуынча, экспозициягә ни өчендер яшь чиге 0+ куелган. Балаларның психикаларын җәрәхәтләмәс өчен, стикер цензурасы кертергә мәҗбүр булганнар.



Ә МЕҢӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Студент инженер булырга хыялланган, ләкин имтиханын бирә алмаган һәм генерал булырга хыялланырга китеп барган.

• • •

Терапевтка кергәч:

– Анализларыгызны карадым. Хәзер интернеттан белешмә алам.

– Мин аны аннан үзем дә карый алам.

– Үзлегеңнән дәваланырга ярамый!

• • •

Хатыны – иренә:

– Синнән хатын-кызлар хушбуе аңкый.

– Ирләрнеке булмавы шәбрәк бит бит инде.

• • •

Табиб – авыруга:

– Димәк, өч ай эмисез, тартмыйсыз, хатыннар белән ресторанга йөрмисез!

– Бу терелгәнче генәме, доктор?

– Миңа дәвалау өчен тиешле акчаны түләп бетергәнче.

• • •

– Әбекәем, нигә синең колакларың бик зур?

– Соң бит, бәбекәем, ТВда да колакка токмачларның бәләкәен асмыйлар.

• • •

– Әти, кемнәр авырттырыбрак тешли: этләрме, мәчеләрме?

– Бәяләр, улым.

• • •

Урта яшь – иртәгә яхшырак булыр дип ышана торган чак.

• • •


Балконымны чистарта башлаганчы сәясәттән дә пычрак нәрсә юк дип уйлаган идем.

• • •

Мәчтүрә түтәйдән киңәш: "Әгәр ireңне ирләр белән сыра эчәргә җибәрмәсәң, ул хатыннар белән шампанский эчә башлаячак".



Максим СМАГИН



Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Виктор ФЁДОРОВ

Вячеслав ШИЛОВ



Александр СЕРГЕЕВ



Дамир МОРТАЗИН

Йолдызлар җыены

– Карале, мин кичә телевизордан шундый шәп кино карадым!

– Исеме ничек?

– Хәтердә түгел. Анда теге бик хәтәр артист уйнаган иде...

– Нинди?

– Теге инде, теге... бишенче хатыны белән аерылган... кем соң әле?.. Бөтен кеше белә аны, бик тә танылган... Җә, ярар, соңыннан әйтермен, искә төшергәч...

– Үзе генә уйный торганмы?

– Юк инде! Бер чибәр артистка белән, анысы да шәп уйный аның. Бер тапкыр шуны режиссеры бүлмәсендә тотканнар иде, үбешеп торган чагында.

– Баш режиссерны сөйлисеңме син?

– Әйе, әйе, шул пеләшне әйтәм инде. Бөтен дөньяга даны чыкты бит – Малаховка ярты елга җитәрлек тапшыру ясарга була иде...

– Ул йолдызның фамилиясе ничек иде?

– Әллә шунда "М"га, әллә "Ш"га башлана... Кыскасы, бик зур йолдыз инде. Син аны беләсең... Кинода да төшкәне бар...

– Киносы нәрсә турында соң?

– Бик кызык эчтәлекле! Ярый, сөйлим бераз. Баш герое – күргәнең бар синең аны, барлык бандитларны кырып сала. Ә әлеге йолдыз чибәркәй "М" гамы, "Ш" гамы башланган, моңа гашыйк була. Соңыннан алар туй ясыйлар. Кыскасы, хэппи энд...

– Шул гынамы?

– Юк әле... Соңыннан, фильмны карагач, фикерләшүләр булды. Танылган персонажлар белән ток-шоу уздырылды. Анда әле танылган бер рәссам да катнашты...

– Анысы кем?

– Әлеге дә баягы, син аны беләсең, соң инде үзенең кайнанасына өйләнгән, үзенә пластик операция ясаткан...

– Рәшидәне әйтәсеңме?

– Юк ла инде, Рәшидәне мин бит беләм – ул көн саен иртәнге тапшыруда ашарга пешерергә өйрәтә... Әле анда җырчы Мәйме, Ләйме утырды, фамилиясе юк...

– Тутыймы?

– Шулай бугай, ул продюсерына кияүгә чыгып, аның гаиләсен таркаткан...

– Тагын кемнәр булды?

– Бер блогер...

– Болганып йөрүчеме?

– Аларны бөтен ил белә. Син генә белмисең икән блогерларны. Аннан соңгы сайлаулардан соң калкып чыккан бер политик, ул бөтен телеканалларда кысылып йөри. Тагын бер режиссер бар иде. Монысының да фамилиясен хәтерләмим, фильмнарын караганым булмады. Шулай да би-и-к күренекле режиссер! Ярар, синең белән лыгырдап торырга вакытым юк. Ашыгам, анда хәзер "Дом-2" башлана. Менә анда инде йолдыз өстендә – йолдыз!



Александр БРЮХАНОВ

Җайлы тормыш

Аны бусагада ук хатыны каршы алды.

– Акча алып кайттыңмы?

– Алып кайттым, – диде ул һәм юлга аркылы торган хатынына кесәсеннән акча чыгарып бирде. Тегесе аны санап чыкты һәм башын селкеде.

– Уз, чишен, кулыңны ю да ашарга утыр. Аш – өстәлдә, телевизор тоташтырылган, урын җәелгән...

Ул хатынының ваннада кранның тамып торуы һәм киштә кагып куярга кирәклеге турында сөйләнүен тыңлый-тыңлый яхшылап ашады һәм сорап куйды:

– Ә син үзең хезмәт хакы алдыңмы соң? Киштә куярга шөреп-мазар алырга кирәк... Хатыны аңа акча сузды. – Хәзер кранны рәтлим, – диде ул. – Ә син телевизор карый тор... Аннан соң йокларга ятырбыз...

– Нәрсә инде, син, бөтен нәрсәне шулай гадиләштерәсең, – дип сукранды хатыны. – Ә хисләр, тойгылар кайда? Ә назлы сүзләр, иркәләүләр?

– Нинди сүзләр, нинди хисләр? Бик җайлы яшибез бит... Нигә катлауландырырга тормышны?

Василий АЛЕКСАНДРОВ



ПИРАТЛАР ТОРМЫШЫННАН

Валерий ТАРАСЕНКО



Ринат БӘШИРОВ



Илсирә ВӘЛИУЛЛИНА

КЫШ БАБАЙ...

Яңа ел килеп җитәсен
Кыш бабакай белә, ди.
Тиздән барлык кешеләрне
Котлар өчен килә, ди.

Ни теләсәң, шуны әзли,
Матур сөйли, көлә, ди.
Тик биюен, җырлаганын
Чутка сала: "Түлә", – ди.

Унбиш минутка килүе
Алты йөз сум тора, ди.
Акчаңны күбрәк түләсәң,
Барсын эшлим, сора, ди.

Интернет тулы реклама,
Теләсәң кайсын чакырт –
Төрле милләт Кыш бабае
Татар, урысы, башкорт...

Ә без үскәндә Кыш бабай
Бәйрәмгә бушка килде.
Һәрберебез бу бабайның
Юмарт икәнен белде.

Ни өчендер, Кыш бабай да
Табыш ярата хәзер.
Акча күп түләсәң генә
Килеп котларга әзер...



Александр АЛЁШИН



Клара БУЛАТОВА

КЛАРА КЫТЫКЛАРЫ

• • •

Акча! Акча! Шуннан башка
Һич нәрсә юк хәзер башта.
Шуны туглый "Акча! Акча!"
Экранда да, әнә, Патша!

Кәгазь, каләм юкка түгел,
(Алар да юк – акча юкка!)
"Кыскалыкта – осталык!" дип,
Мин дә күчтем дүрт юллыкка.

Дүрт юл нигә кирәк әле?!
Ул озынга сузылган бит.
Мин бүгенге көн хәлләрен
Өч юлга да сыйдырам бит.
Мәсәлән:
Ник аны көтәм инде?..
Килеп җитмәгән пенсиям
Ашалып беткән инде.

• • •

Зыялыйлар йөри сызланып:
Эче-тышы кадерсезгә калган,
Укымышлы башын кызганып.

• • •

Иске офисны ябалар, яңа бизнес ачалар,
Урлыйлар, тотылалар – түлиләр,
котылалар,
Безне алдап барчасы, илне талап качалар.

• • •

Хөкүмәткә керем чыганагы өч кенә –
Фатир хакы, налог, штраф.
Бүтән нәрсә юк бит һич менә...

• • •


Түрәләрнең яшәү рәвеше дә
Өч "С"тан тора шулай:
Спорт, Сауна, өченчесе – Секс бугай.

• • •

Бу кытыклар өч юлга да,
Әйе, сыярлык.
Илгә-көнгә яла ягу түгел – чынбарлык.



Лотфулла НАСЫЙРОВ, «Чаян» № 22, 1980.



– Бөтен эчем яна!

Александр АЛЁШИЧЕВ, «Чаян» № 12, 1979



ЙӨЗ ГРАММ

Кодрәтең киң, бөек йөз грамм!
Сиңа җырлыйм мәдхия мин.
Җан дәвасы, шифа бит син,
Башымны сиңа иямен.

Салгач, дөнья гүзәллеге
Тарта басу, киң кырларга.
Теләк туа күкрәк киереп
Шул кырларда бер җырларга...

Бөтен дөнья – гөлбакча күк,
Тирә-юнем – алсу чәчкә.
...Яхшы фикер килеп куя:
Нигә бераз өстәмәскә?..

Тагын йөз грамм!
Уен-көлке,
Җыр-биюдән бетә тыннар.
Аннан – тагын, тагын йөз грамм,
Аннан китә кыз-хатыннар...

...Хәлдән таеп иртә таңда
Диваныма кайтып авам.
Баш — тубал күк...
Бәхет өчен
Җитми бары тагын йөз грамм!

Ринат АБЗАЛОВ

Ришат МИРЗАЯНОВ





Алексей МАМАЕВ

Ояты ни тора...

Камил Шакирович – районда икенче кеше. Яшәгән йортына, йөри торган транспортына килгәндә, алары да беренченекеннән әллә ни ким түгел. Болардан тыш, ул авылдагы үзе туып-үскән йортны да матурлап, төзекләндереп чыкты. Мунчасына да газ, су кергән, хәтта идәннәре дә җылытыла торган итеп эшләнгән. Гаҗәпләнеп әйтү түгел, булдыра. Шул гына. Хәзер бу төп йортта 84 яшьлек әниләре яши. Узган елга чаклы үз көнен үзе күреп, йөгереп йөри иде әле карчык. Бәрәңге бакчасында эт эчәгенә эләгеп, егылып кулын имгәткәч кенә балалары чиратлашып кайтып-китеп йөри башладылар. Атна-ун көнгә, берәр кичкә булса да улы Камил Шакирович та хатыны белән әнисе янына, төп йортка кайтып куна. Тик бу матур өйнең бер кимчелеге бар. Заманча итеп эшләнгән, унитазлы бәдрәфе юк. Улы бүген ясап чыгарга да риза, тик әниләре каршы. "Өйдә йомыш үтәп утырыр хәлем юк, – ди. – Мин үлгәч ясарсыз", – ди. Бетте-китте, берни эшли алмыйсың. Кысталганнарга ишегалдындагысына йөрергә туры килә. Үзегез беләсез, Мөслим, Сарман, Минзәлә якларында урыс капкалар юк бит. Шакировичларның ишегалды да ап-ачык, кемнең нишләп йөргәне әллә каян күренеп тора. Шуңа күрә комган тотып чыгу кайберәүләргә уңайсызлык тудыра. Камил Шакирович исә иртәрәк кайтып китү ягын карый, аннары аның планерка үткәрү кебек җаваплы эшләре дә иртәнге якта.

Шулай беркөнне М7 трассасы буйлап үтеп баручы Чаллы гаишниклары авыл ягыннан "очып" килүче ак джипны күреп алалар һәм туктатып кызыксынмакчы булалар. Ак "Лексус"та җилдерүче шофер – Камил Шакирович, тегеләрнең кабалана-кабалана машиналарыннан чыкканын күрмәмешкә салышып, узып китә. Ә тегеләр аны куа чыга. Кая инде Тольятти машинасына мондыйлар белән ярышу. Шулай да алар үз каналлары аша машинаның кемнеке икәнлеген ачыклыйлар, ун минут дигәндә, каттә генә итеп төзелгән коттедж каршындагы ак машина янына килеп туктыйлар. Әмма өйгә узарга батырчылык итмиләр. Дөресен әйтик, автомобиль хуҗасы да озак көттерми, ун-унбиш минут дигәндә, капкадан килеп чыга, капитан белән күрешә, аңа правасын суза, машинасына төртеп күрсәтә. Аннары:

– Иркенләп кәкәй итәргә дә мөмкинлек бирмисез, егетләр, ә, – дип елмая да, – планерка үткәрәсем бар, – дип китеп бара. Тегеләр дә Ак машина артыннан кузгала. Шактый гына дәшми баргач, капитан иптәшенә:

– Әйттем мин сиңа артына терәлгәндер, дип. – Ә син, әйдә, туктатабыз дигән булып, һаман шигеңне белдерәсең... Гомере буе МВДга хезмәт итеп булмас. Йомышың төшеп, болар каршына да килергә туры килмәгәе... Таныса, ояты ни тора, – дип сөйләнеп ала.

Мидхәт САДЫЙКОВ

Рушания ГЫЙЛӘҖЕВА

КҮРШЕ МУНЧАСЫ

Авылда яшәгән ике күрше:
Илдусның хатыны – Гөлчирә,
Каршыдагы йортта – адаш хатын.
Гөлчирәләр рәхәт көн сөрә.

Шулай, берчак Илдус Гөлчирәсе
Кунак җыя. Ничек булдыра!
Бераз тамак ялгап алгач, болар
Җыйнаулашып чыга болдырга.

Хөрмәт итеп яккан мунчасына
Кунаклары, шатланып керә.
Соңгы пар җибәреп, бер кунагы
Салкын суны тәмам бетерә.

Янәшәдә күрше булып яши
Хәләл җефетле бер Нургали,
Мунчалары булмаганга, алар
Күрше мунчасына кергәли.

Нургалинең җете кызыл йөзе,
Борыны да, кып-кызыл муен,
Гөлчирәгә багып, күзен ата:
Хисләрен белдерергә уе.

"Хуш, рәхмәт", – ди, – мунча хөрмәтенә,
Рәхәт булды, бигрәк шәп, кызу,
Кайнар суы гына калган иде,
Юк иде анда тик салкын су!"

Кунаклары аптырашка кала:
Ничек инде бетсен салкын су?
Ә Нургали хатынына багып,
Җикеренә: "Нинди хәл соң бу?

Нишләп инде, кайнар суны, ташып,
Салкын суны җыеп куймадың?
Әллә мине чын ахмакка санап,
Тилергән мәхлук дип уйладың?"

Ә хатыны, акланыплар, шулчак
Аткан уктай җавап җибәрә:
"Соң бит мин бүген иртән мунчаны
Яктым икенче Гөлчирәдә!"

Нургали, ишеткәч шул сүзләрне,
Салып, ата юеш сөлгене...
Әнә иртән мунча бурасын ул
Ясап ята – үзе түгелме?



САТИРА һӘМ
ЮМОР ЖУРНАЛЫ
1923 елдан чыга.

№ 1 (1890) гыйнвар 2020

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе
«ТАТМЕДИА»
акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре,
Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләре агентлыгы
ярдәмендә оештырылган.
Журнал
Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы,
йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша
языла алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның
ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү
хокукына ия.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 10.01.2020 ел.
Тираж –1126 Заказ О-3664

Редакциянең адресы: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.


Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле

16+

Уйна да, уйла да!

ЧАЯН

- ДРАМАТУРГ ГАФУР ...
- ХАЛЫК ЖЫРЫ
- "БАЛА" ИСКЕЧӘ
- 2
- РАЙОН ҮЗӘГЕ
- ЧӘЧӘК ТӨСЕ
- 12
- ЖЫРЧЫ РАМИЛ ...
- УРМАН КОШЫ
- ИКЕНЧЕ НОТА
- "БЕР ТАУДА ... ЧИШМӘ"
- ГӨБӘДИЯДӘ БУЛА
- 5
- ТЕАТР АРТИСТЫ РИНАТ ...
- ӘЛМӘНДӘРНЕҢ АВЫЛЫ
- 7
- "ИР КАНАТЫ"
- ЖАННА Д' ...
- "ТУГАН ... ТАШЛАМАГЫЗ"
- АТ ДИРБИЯСЕ
- АУДИОТЕХНИКАДА БЕР КАНАЛЛЫ ТАВЫШ
- КИТАП КУЯРГА УҢАЙ
- "... ЧӘЧӘКЛӘР"
- ... ЮЛ
- ӘНӘЛЕ БОТАК
- АЛТЫНЧЫ НОТА
- 11
- 14
- "АРАЛАРДА ЮЛЛАР ..."
- "СУТЫЙ"
- НАМАЗГА ЧАКЫРУ
- ЗӨЛФӘТНЕҢ ИЖАТ ЧИШМӘСЕ
- ЧИБӘР, ГҮЗӘЛ
- КЫР, БАСУ
- ПРЕЗИДЕНТ ӨМЕРЕ
- 10
- 6
- 4
- КӨЧЛЕ, НЫК
- "ЭШ КҮРСӘТКӘН ... ИЛ ОНЫТМАС"
- ПЬЕСАНЫҢ ӨЛЕШЕ
- ... СҮЗЕ БЕР БУЛЫР
- "ТАМБОВ УРМАННАРЫ АГАЧЫ"
- 8
- САМОЛЁТ
- ИҢ ЯКЫН КЕШЕ
- СОВЕТ АВТОМОБИЛЕ
- 3
- 9
- ИР БАЛА
- 1
- 13









Ринат АБЗАЛОВ төзеде



1. Үзеңнең киләчәгеңә ничек мөлкәт салырга мөмкин?

2. Илебездә җитештерелгән машиналарга түрәләр кайчан күчеп утырачак?

3. Тарттырылган түшәмнәрнең уңайсызлыгы.

4. Акча өчен йоклый торган борынгы һөнәр вәкиле.

5. Нәрсә ул икътисадый кризис?

6. Кемнәр ул вегетарианнар?

7. Простофиля кем ул?

ҖАВАПЛАР

1. Җәйге киемгә мең тәңкә акча тыгып. 2. Суд тикшерүеннән соң, изоляторга алып барганда. 3. Өстәге күршеләргә шакып булмый. 4. Каравылчы. 5. Хезмәт хакы алдындагы атна. 6. Гадәти булмаган ризыклар кулланучы кешеләр. 7. Пугачёвасыз Киркоров.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исеме укыгыз. Журналыбызның 12 нче санында басылган чаянвордның тикшерү сүзе — **«САМАВЫР КУЙДЫМ».**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:
Г. БАҺАВЕТДИНОВ (Чаллы),
М. МӨХӘММӘТҖАНОВ (Казан),
М. НУРЕТДИНОВ (Сарман),
Б. ШӘЙХЕТДИНОВ (Алексеевский р-ны, Урта Тигәнәле ав.)
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Җиңүчебез – Урта Тигәнәледән
Бәдертдин ШӘЙХЕТДИНОВ!

СӘЕР КЕШЕЛӘР

Сергей ЕРМИЛОВ



Игорь КИЙКО





Ринат АБЗАЛОВ

Илдар НӘФИЕВ





